**МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.05.2016 № 11-60

г. Казань

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе турында

“Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль закон, “Коррупциягә каршы көрәш турында” 25 декабрь, 2008 ел, № 273-ФЗ Федераль закон, “Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссияләр турында” 1 июль, 2010 ел, № 821 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, “Дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе турында” 25 август, 2010 ел, № УП-569 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе турында нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) аппаратының (Мәкъсудова Г.Х.) һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының (алга таба –

Казначылык департаменты) (Старцев И.А.) кадрлар бүлекләре начальникларына тәэмин итәргә:

Министрлык аппаратында һәм Казначылык департаментында дәүләти гражданлык хезмәткәрләрен, шулай ук, хезмәт контрактын төзегәндә, гражданнарны бу боерык белән таныштыруны;

Бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрүне.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры М.Д. Фәйзрахмановка йөкләргә

**Министр** **Р.Р.Гайзатуллин**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.05.2016 ел, № 11-60 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмә

1.1. Бу Нигезләмә “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль закон, “Коррупциягә каршы көрәш турында” 25 декабрь, 2008 ел, № 273-ФЗ Федераль закон, “Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссияләр турында” 1 июль, 2010 ел, № 821 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, “Дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе турында” 25 август, 2010 ел, № УП-569 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә

оештырыла торган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе (алга таба - Комиссия) булдыру һәм аның эшчәнлеген җайга салу тәртибен билгели.

1.2. Комиссия үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Комиссиянең төп бурычы булып тора:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре, Министрлык) мәнфәгатьләр бәрелешен кисәтү яки җайга салу турында чикләүләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен тәэмин итүдә, шулай ук “Коррупциягә каршы көрәш турында” 25 декабрь, 2008 ел, № 273-ФЗ Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә билгеләнгән бурычларын (алга таба – хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләр һәм (яки мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләр) үтәүне тәэмин итү;

Министрлыкта коррупцияне кисәтү чараларын хәл кылуда ярдәм итү.

1.4. Комиссия Министрлыкта дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын (алга таба – дәүләт хезмәте вазыйфалары) биләүче дәүләт хезмәткәрләренә (вазыйфаларына билгеләү һәм вазыйфаларыннан азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан хәл ителә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән тыш) карата хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләрне карап тикшерә.

1.5. Вазыйфаларына билгеләү һәм вазыйфаларыннан азат итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан хәл ителә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә карата хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләрне үтәүгә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында оештырылган Хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу комиссиясе тарафыннан карала.

1.6. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турында хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карап тикшерми, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр үткәрми.

II. Комиссия составы

2.1. Комиссия составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзаларыннан министр билгели торган Комиссия Рәисе, Комиссия Рәисе урынбасары, Комиссия секретаре һәм Комиссия әгъзалары керә. Комиссиянең барлык әгъзалары каралар кабул ителгәндә бер үк төрле хокукларга ия. Комиссия рәисе югында аның бурычларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына керә:

а) министрның беренче урынбасары - Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры (комиссия рәисе), Министрлыкның коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү эшенә җаваплы вазыйфаи заты (комиссия секретаре), кадрлар бүлеге начальнигы, юридик бүлек начальнигы, Министрлыкның һәм Министрлыкның Казначылык департаментының башка бүлекләренең министр тарафыннан билгеләнә торган дәүләт хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча подразделениесе вәкиле;

в) эшчәнлеге дәүләт хезмәте белән бәйле булган фәнни оешмалар, һөнәри мәгариф оешмалар, югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирүче оешмалар вәкиле (вәкилләре).

2.3. Министр Комиссия составына түбәндәгеләрне кертү турында карар кабул итәргә мөмкин:

а) “Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” 14 октябрь, 2005 ел, №103-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 22(1) статьясы нигезендә Министрлык каршында оештырылган Иҗтимагый совет вәкилен;

б) Министрлыкта билгеләнгән тәртиптә эш итүче профсоюз оешмасы вәкилен.

2.4. Бу Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы “б” һәм “в” пунктчаларында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына министр запросы нигезендә, тиешле органнар һәм оешмалар белән үзара килешенеп, билгеләнгән тәртиптә кертелә.

2.5. Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләмәүче Комиссия әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан ким дигәндә дүрттән бер өлеш тәшкил итәргә тиеш.

2.6 Комиссия составы Комиссия тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясардай мәнфәгатьләр бәрелеше килеп чыгу ихтималы булмаслык итеп формалаштырыла.

2.7. Комиссия утырышларында тавыш бирү хокукы белән катнаша:

а) үзенә карата Комиссия тарафыннан хезмәт урынына карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләрне үтәү мәсьәләсе карап тикшерелә торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Министрлыкта үзенә карата Комиссия тарафыннан әлеге мәсьәлә карап тикшерелә торган дәүләт хезмәткәре биләгән шундый ук дәүләт хезмәте вазыйфаларны биләүче ике дәүләт хезмәткәре;

б) Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм Комиссия тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә алырдай белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; кызыксынулы оешмалар вәкилләре; үзенә карата Комиссия тарафыннан хезмәт урынына карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләрне үтәү мәсьәләсе карап тикшерелә торган дәүләт хезмәткәре вәкиле – үзенә карата Комиссия тарафыннан әлеге мәсьәлә карап тикшерелә торган дәүләт хезмәткәренең яки Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының үтенечнамәсе нигезендә, Комиссия утырышы көненә кимендә өч көн кала һәр аерым очрак буенча Комиссия Рәисе тарафыннан кабул ителә торган карар нигезендә.

2.8. Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан ким дигәндә өчтән ике өлеше катнашкан очракта, Комиссия утырышы, узды, дип санала. Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары катнашында гына утырыш үткәрергә ярамый.

2.9. Комиссия әгъзасының Комиссиянең көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне карап тикшергәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерү ихтималы булган турыдан-туры яки читләтеп шәхсән кызыксынуы килеп чыккан

очракта, Комиссия әгъзасы утырыш башланганчы бу хакта белдерүгә бурычлы. Бу очракта Комиссиянең тиешле әгъзасы әлеге мәсьәләне карап тикшерүдә катнашмый.

III. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия үткәрүгә нигезләр булып тора:

а) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын һәм дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт урынында тәртибенә карата таләпләрне үтәвен тикшерү йомгаклары буенча министрның түбәндәгеләрне дәлилләгән тикшерү материаллары белән таныштыруы:

дәүләт хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 30 декабрь, 2009 ел, № УП-702 Указы белән расланган керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматларны, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында нигезләмәдә күздә тотылган ялган яки тулы булмаган мәгълүматлар тапшыру;

дәүләт хезмәткәренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки- мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәве турында;

б) Министрлыкның кадрлар сәясәте бүлегенә яки коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү эшенә җаваплы затка Министрлыкның норматив-хокукый акты нигезендә билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрнең алынуы:

Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән, Министрлык боерыгы белән расланган, Министрлыкта дәүләт хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы мәгълүматлар һәм иренең (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп иткән Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән гражданинның коммерцияле яки коммерциясез оешмада хезмәт килешүе шартларында вазыйфа биләүгә яки коммерцияле яисә коммерциясез оешмада гражданлык-

хокук килешүе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирүе турында мөрәҗәгате (дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел узганчы, әлеге оешма белән дәүләти идарәнең аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән очракта);

дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр аркасында үзенең иренең (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыра алу мөмкинлегенә ия булмавы хакында гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең “Затларның аерым категорияләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны һәм аларга ия булуны, “тере” акчаларны һәм кыйммәтләрне саклауны тыю турында” 7 май, 2013 ел, № 79-ФЗ Федераль закон таләпләрен, территориясендә счетлары (вкладлар) сакланыла торган чит ил дәүләте законнары нигезендә, әлеге чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан арест салыну, эш итүне тыюга бәйле рәвештә, чит ил банкында “тере” акчалары һәм кыйммәтләре сакланылуга һәм (яки) чит ил финанс инструментларына ия булуына, яисә аның ихтыярына яки иренең (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйсез башка сәбәпләр аркасында, үтәү мөмкинлегенә ия булмавы хакында гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китергән яки китерә алу ихтималы булган шәхси кызыксынуының килеп чыгуы турында уведомлениесе;

в) министрның яки Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләрне үтәүне яисә Министрлыкта коррупциягә каршы көрәш чараларын хәл итүгә кагылышлы танытмасы;

г) министрның дәүләт хезмәткәре тарафыннан “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүенә контрольлек итү турында” 3 декабрь, 2012 ел, № 230-ФЗ Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә күздә тотылган дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар тапшыруын дәлилләгән тикшерү материаллары белән таныштыруы;

д) “Коррупциягә каршы көрәш турында” 25 декабрь, 2008 ел, № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясындагы 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 статьясы нигезендә Министрлыкка коммерциясез яки коммерцияле оешманың Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын

биләгән гражданин белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтү) хезмәт яки гражданлык-хокук килешүен төзү турында уведомление алыну, әлеге оешма белән дәүләт идарәсенең аерым функцияләре Министрлыкта вазыйфа биләгән чорда башкарылган вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән очракта, Комиссия тарафыннан әлеге гражданинга элегрәк әлеге оешма белән хезмәт һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләренә керүдән баш тартылуы шартларында яки мондый гражданинга коммерцияле яки коммерциясез оешмада гражданлык-хокук килешүе шартларында эшләр башкаруга коммерцияле яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләүгә ризалык бирү мәсьәләсе Комиссия тарафыннан карап тикшерелмәгәндә.

3.2. Бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин тарафыннан Министрлыкның кадрлар бүлегенә яки коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эшенә җаваплы затка тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә күрсәтелә: гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, яшәү урыны адресы, дәүләт хезмәтеннән киткән көннән соңгы ике ел эчендә биләгән вазыйфалары, коммерцияле яки коммерциясез оешманың атамасы, урнашу урыны, эшчәнлеге, дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән чорда гражданин тарафыннан башкарылган вазыйфаи (хезмәт) бурычлары, коммерцияле яки коммерциясез оешмага карата дәүләт идарәсе функцияләре, килешү төре (хезмәт яки гражданлык-хокук) аның күздә тотылган гамәлдә булу срогы, килешү буенча эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтү) түләү суммасы. Министрлыкның коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эшенә җаваплы зат тарафыннан мөрәҗәгать карап тикшерелә, аның нәтиҗәләре буенча, “Коррупциягә каршы көрәш турында” 25 декабрь, 2008 ел, № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясындагы таләпләреннән чыгып, мөрәҗәгатьнең асылы буенча нигезле бәяләмә әзерләнелә.

3.3. Бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәтеннән китүне планлаштырган дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылырга мөмкин, һәм ул Комиссия тарафыннан бу Нигезләмәгә туры китереп карап тикшерелергә тиеш.

3.4. Бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “д” пунктчасында күрсәтелгән уведомление Министрлыкта коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эшенә җаваплы зат тарафыннан “Коррупциягә каршы көрәш турында” 25 декабрь, 2008 ел, № 273-ФЗ Федераль законның 12

статьясындагы таләпләрен үтәмәү турында нигезле бәяләмә әзерләүне хәл итүче, коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү эшенә җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан карап тикшерелә.

3.4.1. Бу Нигезләмәнең 16 пунктындагы “б” пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән уведомление Министрлыкта коррупцион һәм башка хокук бозуларның кисәтү эшенә җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан карап тикшерелә, әлеге вазыйфаи зат уведомление карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмә әзерли.

3.4.2.Министрлыкның коррупцияне һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча җаваплы вазыйфаи заты, бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында яки 3.1 пунктының “б” пунктындагы бишенче абзацында һәм “д” пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмә әзерләгәндә, мөрәҗәгатьне яки уведомлениене тапшырган дәүләти гражданлык хезмәткәре белән әңгәмә коруга, аннан язмача аңлатмалар алуга хокуклы. Мәгълүмат алу өчен Министрлык тарафыннан дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынулы оешмаларга запрослар җибәрелергә мөмкин. Мөрәҗәгать яки уведомление, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар, мөрәҗәгать яки уведомление алынганнан соң җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Запрослар җибәрү очрагында, мөрәҗәгать яки уведомление, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки уведомление алынганнан соң 45 көн эчендә тапшырыла. Әлеге срок Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма 30 көнгә генә.

3.5. Комиссия рәисе үзенә Комиссия утырышын үткәрүгә нигезләрдән торган мәгълүматлар алынганда:

а) 10 көн эчендә Комиссия утырышы датасын билгели. Шул ук вакытта Комиссия утырышы датасы әлеге мәгълүмат алынганнан соң 20 көннән дә соңга калмыйча билгеләнергә тиеш, бу Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында күздә тотылган очраклардан тыш;

б) Комиссия тарафыннан үзенә карата хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләрне үтәү турында мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында катнашучы башка затларны Министрлыкның кадрлар бүлегенә яки коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эшенә җаваплы затка алынган мәгълүматлар белән, шулай ук әлеге мәгълүматларны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) утырышка бу Нигезләмәнең 2.7 пунктындагы “б” пунктчасында күрсәтелгән затларны чакыру турында үтенечнамәне карап тикшерә, аларны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карап тикшерү турында (карап тикшерүдән баш тарту турында) карар кабул итә.

3.6. Бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карап тикшерү буенча Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр, милек һәм мөлкәт характерындагы бурычлар турында мәгълүматлар тапшыру өчен билгеләнгән срок чыкканнан соң бер айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

3.7. Бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “д” пунктчасында күрсәтелгән уведомление, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карала.

3.8. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, үзенә карата хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләрне үтәү турында мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре яки Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин катнашында үткәрелә. Дәүләт хезмәткәре яки гражданин Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләнүе турында бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасы нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки уведомлениедә күрсәтә.

3.8.1. Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда дәүләт хезмәткәре яки гражданинның катнашыннан башка гына үткәрелергә мөмкин:

а) бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасында күздә тотылган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки уведомлениедә дәүләт хезмәткәренең яисә гражданинның Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләнүе турында күрсәтелмәгәндә;

б)Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләүче дәүләт хезмәткәре яки гражданин үзләренә утырышны үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешенчә хәбәр ителгән булса да, Комиссия утырышына килмәгәндә.

3.9.Комиссия утырышында Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасы биләгән дәүләт хезмәткәренең яки гражданиның (аларның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка чыгарылган мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

3.10. Комиссия әгъзаларының һәм Комиссия утырышында катнашкан затларның Комиссия эше барышында үзләренә мәгълүм булган мәгълүматларны таратуга хокукы юк.

3.11.Комиссия, бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “а” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан, Татарстан Республикасы Президентының 30 декабрь, 2009 ел, №УП-702 Указы белән расланган, Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыру хакында нигезләмәгә туры китереп тапшырылган мәгълүматларның дөрес һәм тулы булып торуын билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәренең бу пунктның беренче абзацында атап үтелгән нигезләмәгә туры китереп тапшырылган мәгълүматларының дөрес түгеллеген һәм (яки) тулы булып тормавын билгеләргә.Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы кулланырга тәкъдим итә.

3.12. Комиссия, бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “а” пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләрне үтәгәнлеген билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәренең үзенә карата хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләрне үтәмәгәнлеген билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләрне бозуга юл куярга ярамавын күрсәтергә яки дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җавап чарасы кулланырга тәкъдим итә.

3.13. Комиссия, бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданинга коммерцияле яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләүгә яки гражданлык-хокук килешүе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирә, әлеге оешма белән дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) вазыйфасына кергән очракта;

б) гражданинга коммерцияле яки коммерциясез оешмада гражданлык-хокук килешүе шартларында вазыйфа биләүгә яки эшләр башкаруга ризалык бирүдән, әлеге оешма белән дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) вазыйфасына кергән очракта, баш тарта һәм үзенең баш тартуын нигезли.

3.14. Комиссия бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең үзенең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшырмау сәбәбенең объектив һәм игътибарга лаек булып торуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренең үзенең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшырмау сәбәбенең объектив һәм игътибарга лаек булып тормавын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә әлеге мәгълүматларны тапшыру буенча дәүләт хезмәткәренә карата чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәренең үзенең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшырмау сәбәбенең объектив булып тормавын һәм әлеге мәгълүматларны тапшырудан читләшү ысулы булып торуын танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җавап чарасы кулланырга тәкъдим итә.

3.15. Комиссия бу нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең “Затларның аерым категорияләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны һәм аларга ия булуны, “тере” акчаларны һәм кыйммәтләрне саклауны тыю турында” 7 май, 2013 ел, № 79-ФЗ Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулык ясый торган сәбәпләрнең объектив һәм ихтирамга лаек булып торуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренең “Затларның аерым категорияләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны һәм аларга ия булуны, “тере” акчаларны һәм кыйммәтләрне саклауны тыю турында” 7 май, 2013 ел, № 79-ФЗ Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулык ясый торган сәбәпләрнең объектив һәм игътибарга лаек булып тормавын танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәтләренә карата конкрет җавап чарасы күрергә тәкъдим итә.

3.15.1 Комиссия, бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелеше булмавын танырга;

б) дәүләт хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуының мәнфәгатьләр бәрелешенә китерүен яки китерә алуын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яки) министрга мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу яки аның килеп чыгуына юл куймау буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәренең мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләрне үтәмәгәнлеген танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җавап чарасы күрергә тәкъдим итә.

3.16. Комиссия, бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “в” пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча тиешле карар кабул итә.

3.17. Комиссия, бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “г” пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүенә контрольлек итү турында” 3 декабрь, 2012 ел, №230-ФЗ Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә тапшырылган мәгълүматларының дөрес һәм тулы булып торуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренең “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүенә контрольлек итү турында” 3 декабрь, 2012 ел, №230-ФЗ Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә тапшырылган мәгълүматларының дөрес түгеллеген һәм тулы булып тормавын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә һәм (яки)

чыгымнарга контрольлекне хәл итү нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратура органнарына һәм (яки) тиешле компетенциядәге башка дәүләт органнарына җибәрергә тәкъдим итә.

3.18. Комиссия, бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “д” пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданинга коммерцияле яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләүгә яки гражданлык-хокук килешүе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирергә, әлеге оешма белән дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) вазыйфасына кергән очракта;

б) гражданинның коммерцияле яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләвенең яки гражданлык-хокук килешүе шартларында эшләр башкаруының “Коррупциягә каршы көрәш турында” 25 декабрь, 2008 ел, №273-ФЗ Федераль законның 11 статьясындагы таләпләрен бозуын билгеләргә.

3.19. Комиссия, бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “а”, “б”, “г”, “д” пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карап тикшерү йомгаклары буенча, нигезләр булганда, бу Нигезләмәнең 3.11-3.15.1, 3.17, 3.18 пунктларында күрсәтелгәннән үзгә карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карарны кабул итүгә нигезләр Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

3.20. Комиссия карарларын үтәү өчен Министрлыкның норматив-хокукый актлары яки министр поручениеләре проектлары әзерләнелергә мөмкин, алар билгеләнгән тәртиптә министрга карап тикшерүгә тапшырыла.

3.21. Бу Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Комиссия карары, Комиссия әгъзалары утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән, яшерен тавыш бирү нигезендә (Комиссия башка карар кабул итмәгән очракта) кабул ителә.

3.22. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары кул куя. Комиссия карарлары, бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча кабул ителә торган карардан тыш, министр өчен тәкъдим итү характерында гына булып тора. Бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карап тикшерү йомгаклары буенча кабул ителә торган карар – мәҗбүри характерда.

3.23. Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелә:

а) Комиссия утырышы датасы, Комиссия әгъзаларының һәм комиссиядә катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре;

б) үзенә карата хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәренең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын күрсәтеп, Комиссия утырышында карап тикшерелә торган һәр мәсьәләнең формулировкасы;

в) дәүләт хезмәткәренә карата куела торган дәгъвалар, аларны нигезли торган материаллар;

г) дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның үзләренә карата куелган дәгъваларның асылы буенча аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) Комиссия утырышын үткәрүгә нигез булып хезмәт иткән мәгълүматлар чыганагы, мәгълүматларның Министрлыкка алыну датасы;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүгә нигез.

3.24. Комиссия утырышы карары белән риза булмаган Комиссия әгъзасы язмача рәвештә үзенең фикерен бәян итүгә хокуклы, әлеге фикер Комиссия утырышы беркетмәсе янына куелырга һәм аның белән дәүләт хезмәткәре танышырга тиеш.

3.25. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе утырыштан соң 7 көн эчендә министрга тулысынча яки аннан өземтә рәвешендә – дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары буенча – кызыксынулы башка затларга җибәрелә.

3.26. Министр Комиссия утырышы беркетмәсен карап тикшерүгә бурычлы, һәм ул үзенең компетенциясе чикләрендә беркетмәдәге тәкъдимнәрне дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында күздә тотылган җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итүдә, шулай ук коррупциягә каршы көрәшне оештыруның башка мәсьәләләре буенча исәпкә алуга хокуклы. Министр Комиссия тәкъдимнәрен карап тикшерү һәм карар кабул итү турында, Комиссия утырышы беркетмәсе үзенә алынганнан соң бер ай эчендә, Комиссиягә язмача рәвештә хәбәр итә. Министр карары Комиссиянең

якындагы утырышында игълан ителә һәм фикер алышынмыйча гына игътибарга алына.

3.27. Комиссия дәүләт хезмәткәре гамәлләрендә (гамәл кылмау) дисциплинаны бозу билгеләрен күргән очракта бу хакта мәгълүмат министрга дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылган җаваплылык чараларын куллану турында мәсьәләне хәл итүгә тапшырыла.

3.28. Комиссия дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл кылмау) административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре күргән очракта, Комиссия рәисе әлеге гамәлне кылу (гамәл кылмау) турында мәгълүматларны һәм бу фактны раслаучы документларны өч көн эчендә хокук саклау органнарына тапшыруга, кирәк булганда, кичекмәстән тапшыруга бурычлы.

3.29. Комиссия утырышы беркетмәсе күчермәсе яки аннан өземтә үзенә карата хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу турында таләпләрне үтәү турында мәсьәлә карап тикшерелгән дәүләт хезмәткәренең личное делосына куела.

3.30. Комиссия секретаре имзасы һәм Министрлык мөһере белән расланган Комиссия карарыннан өземтә үзенә карата бу Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә карап тикшерелгән, Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинга имза салдырып яки аның мөрәҗәгатендә күрсәтелгән адрес буенча почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) Комиссиянең тиешле утырышы үткәрелгәннән соң килгән бер эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

3.31. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларына утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итү, Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышында фикер алышуга чыгарыла торган материаллар белән таныштыру Министрлыкта коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эшенә җаваплы зат тарафыннан хәл ителә.